**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операция уздыру районнары янындагы участокларда Россия Федерациясе дәүләт чиген саклау бурычын турыдан-туры үтәү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) федераль куркынычсызлык хезмәте хәрби хезмәткәрләре гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 елның 4 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 7 июнендәге ПУ-400 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 5 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәп, үзгәреш кертергә: «, шулай ук Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операция уздыру районнары янындагы участокларда Россия Федерациясе дәүләт чиген саклау бурычын турыдан-туры үтәү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) федераль куркынычсызлык хезмәте хәрби хезмәткәрләре гаилә әгъзаларына».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аның үтәлешен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 31 август
№ ПУ-611